СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2018 г. Заинск № 341

**Зәй муниципаль район Советының 2018 елның 13 апрелендә кабул ителгән 279 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге № 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2013 елның 25 июнендәге № 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль район Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль район Советының 2018 елның 13 апрелендәге 279 номерлы карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, Зәй муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.23 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә башкаручы затларны премияләүгә җибәрелә торган акчаларның гомуми күләме айлык акчалата бүләк һәм айлык акчалата бүләкләрдән торган Татарстан Республикасы бюджетыннан хезмәт өчен түләүгә кирә торган максатчан акчалардан тыш, 5 айлык акча күләменнән артмаска тиеш дип билгеләргә».

2. Зәй муниципаль районы Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В. Г. Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р. Г. Кәримов**